**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 4** **28.11.2021**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Үрсай авыл җирлеге составына керүче
Мөслим авылында 2022 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Урсай авыл җирлеге Меслим торак пункты территориясендә 1 теркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар ечен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.
Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- -Мөслим авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декадасы», «Яңа ел»,);
- Мөслим авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга карны механикалаштырып җыю, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү);
- -җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территориясе),территорияне механикалаштырылган чабу хезмәте өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм тример өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту, территорияләрне яшелләндерү чаралары, Мафлар сатып алу һәм урнаштыру.,
- халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, ЗСО чыганакларын тезекләндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәтләр өчен түләү, Мөслим авылында эчә торган суны биохимик һәм бактериологик анализлау үткәрү);
- Мөслим авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш җәю, таш салу, вак таш җәю, Мөслим авылында Гафури урамы, 3 - 27 нче йорт буенча тезелгән килешү буенча түләү);
- Меслим авылы христиан зиратын киртәләп алу, койма ясау һәм урнаштыру.;
- Мөслим авылында урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.
-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Меслим авылы, Гафури урамы, 31 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урсай авыл җирлеге Башлыгы З.Х.Рахимьянова